



ИРЕК МУСИН

# ЯКТЫ МОҢ

Рәссам Ирек Мусин картиналарындагы образлар – табигать балалары. Табигать белән гармониядә яшәүче ул кешеләргә карап яшәү дәрте арткандай була, аларның күзләрендәге якты моң табигать-ананың якты сагышы белән бер дулкынга көйләнгән.

Төсләр дә үзенә бер моң көйли кебек. Кайберләреннән бәллүр көе ишетелә, кайберсе думбыра авазлары белән үзенә чакырып ала. Бәгъзеләре моңлы саз кебек күңелнең иң нечкә кылларын тарткалап кала... «Нәкъ безнеңчә, матур, милли көй» диясе килә бу картиналар янынннан узганда. Төрки тамырлар турындагы тарихи хәтерне дә яңартып җибәрә алар. Киң далалар, ирек хисе, ирекле җил, җил белән узышып чабучы юртаклар, ат өстендәге курку белмәс яугир җайдаклар, нечкә билле сылу кызлар...

Үз халкыңны, аның тарихын, рухи һәм матди мәдәниятен, гореф-гадәтләрен эчке бер тоемлау белән яратыр өчен читтә, башка милләт вәкилләре арасында туып үсәргә кирәк булгандыр Ирек Мусинга. Казахстанның Петропавловск шәһәрендә канат ярган егет 1991 елда Чаллының сәнгать училищесын тәмамлый һәм Казанда яшәп кала. «Татар халкын милләт буларак кына түгел, ә үз кавемем, үз тамырым итеп яраттыра алган, аның тарихы, бүгенгесе белән горурланырга өйрәткән әтием Рәшит Шәех улы белән әнием Фәния Госман кызына рәхмәтлемен. Мин хәзер Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Төбәкләрдә, республикада оештырылган күргәзмәләрдә даими катнашып киләм. Күргәзмәләрне тамаша кылырга килгән кешеләр иҗатымда милли төсмерләрне аерып билгели. Бу исә иҗатчы белән сәнгать сөюче арасындагы диалогны аңлата. Димәк, без бер-беребез белән шушы телдә аңлашабыз. Иҗат кешесе өчен тагын ни кирәк?» – ди рәссам.

Ирек Мусин – хәзерге заман сәнгате халыкара конкурсларында җиңүләр яулаган, сынлы сәнгатьне яратучы зыялылар арасында шактый танылган рәссам. Аның эшләре Россия һәм чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана. Күңелләргә якты моң сала торган рәссамга киләчәктә дә илһамлы иҗат бәхете телик!

Ландыш ӘБҮДӘРОВА